# *Сафиуллина Рушания Баһаутдин кызы*

*Мин, Сафиуллина Рушания Баһаутдин кызы, 1941 нче елның 8 нче декабренда Ювас авылында тудым. Әтием сугыштан исән-имин кайтты. 1919-1921 нче елгы сугышта да булды ул. Ватан сугышында 5 ел хезмәт итеп кайтты.*




*1941нче елны бик кечкенә идем. Ювас мәктәбендә 5 ел белем алдым, 15 яшемдә башта ат фермасында эшләдем, аннары нәселле таналар фермасында эшләп, пенсиягә чыктым. Хезмәт стажым 41 ел. Мактау кәгазләре, “Хезмәт ветераны” таныклыгым, грамоталар, медальләрем дә бик күп. Олыларга, уллары армияләргә киткән кешеләргә сулар китерә идек, идәннәрен юдык, ничек булыша алдык, шулай булыштык инде.*




*Сугыш беткәнен әтием кайткач кына белдем. Әти киткәндә, мин бишектәге бала булганмын. Әтиемне белми калдым. Әтине елый-елый, абына-сөртенә каршы алганым әле дә исемдә. “Әтиең кайтып килә” диделәр дә, олы апам белән, әти каршына йөгереп төшеп, әтинең муенына асылындым, әти кочаклап өйгә алып кайтты. Әти кайткачтын бик куандык.*

*Сугыштан соң, аллага шөкер, әтием бар иде. Без гаиләдә 3 кыз үстек, иң кечесе мин идем. Ярдәмгә мохтаж түгел идек, ашарга, эчәргә бар иде.*



*Кеше нәрсә ашады, без дә шуны ашдык. Кукәрин дә, кычыткан да, бәрәңге яфрагын да, һәммәсен дә ашадык.*

*Хәзерге яшь буынга тырышып укырга, тәртипле булырга, олыларны олыларга, кешене кеше итәргә, ярдәмче булырга кирәк.*